# Башлангыч сыйныфта дәресләрдә проект эшчәнлеге

*Проект эше укучыларның мөстәкыйль эшчәнлегенең бер өлеше булып тора.*

*Сыйфатлы эшләнгән проект – ул эшчәнлекне этаплап дөрес итеп планлаштыру һәм нәтиҗәләрне анализлап бару.*

## Проект эшчәнлегенең түбәндәге этапларын аерып күрсәтергә мөмкин.

- Проект эшен сайлау.
- Оештыру, эш бүленеше.
- Эшне башкару.
- Эш нәтиҗәләрен анализлау һәм матур итеп туплап кую (презентацияләр, чыгышлар)
- Алынган нәтиҗәләр буенча фикер алышу (рефлексия)

# Әйләнә-тирә дәресе,
# 4 нче класс

*« Кеше организмы ничек төзелгән?»*

# Дидактик максат:

**Проект эшчәнлеге кысаларында яңа белем күнекмәләре алу өчен шартлар булдыру**

# Максатлар:

-Кеше организмы төзелешен, органнарның эшчәнлеген өйрәнү;

- үз фикереңне исбатлап күрсәтә белергә өйрәтү:

- Үзеңнең нәтиҗәләреңне башкаларга да җиткерү;

--үз организмың белән гармониядә яшәргә кирәклеген һәркемгә җиткерү.

Сез көчле,
дәртле,
энергияле
булырга телисезме?







Сез күзләрегезнең балкып торуын, тирегезнең – чиста, тавышыгызның яңгыр



торуын, йөрешегезнең ышанычлы булып күренүен телисезме?







Бирем №1.

Кеше организмында нинди органнар бар?

# Бирем №2.

Ни өчен кеше үз организмының төзелешен һәм эшчәнлеген белергә тиеш?

# Бирем №3.

Сезнең организм дөрес үсеш алганмы һәм сезнең авырлыгыгыз буегызга туры киләме.

# 1 нче төркем өчен инструкция :

1. Кеше төзелеше рәсемен карагыз. Аерым органнарны
күрсәтегез, алар кайда урнашуы турында сөйләгез.
2.Куелган сорауга ничек җавап бирерсез .
3.Бер чыгыш ясаучыны әзерләгез.

# 2 нче төркем өчен инструкция:

1. Өстәләдге өстәмә материал белән танышыгыз.
2. Куелган сорауга ничек җавап бирергә кирәклеген уйлагыз.
3. Бер чыгыш ясаучы әзерләгез.

# 3 нче төркем өчен инструкция:

1. Буегызны үлчәгез.
2.Үлчәүгә басыгыз һәм ничә килограмм авырлыкта булуыгызны ачыклагыз.
3. Авырлыгыгызның санын озынлыгыгызның дециметрына бүлегез.
4. Сорау буенча чыгыш ясарга берегез әзерләнегез.

# 9. Рефлексия.



Сәламәт булу – ул зур бәхет.

Сәламәтлегегезгә игътибарлы булыгыз!

# Йомгаклау

Башлангыч сыйныф укучылары өчен проект эшчәнлеге кирәкле һәм мөһим эшчәнлек;
иҗади проект методын укытуның башка актив методлары белән беррәттән уңышлы кулланылырга мөмкин